| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2018 г. Казан № 10-1/кс

Әгерҗе шәһәре кулланучылары өчен «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте тарафыннан бирелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында.

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе шәһәре кулланучылары өчен «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте тарафыннан бирелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларындагы кайнар суга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенә һәркем ңчен ачык булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 2 февралендәге 10-1/кс
номерлы карарына кушымта

# Әгерҗе шәһәре кулланучылары өчен «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте тарафыннан бирелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларындагы кайнар суга тарифлар

| т/б № | Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешма | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы (ике компонентлы) кайнар суга тариф | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | | җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Әгерҗе муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 36,46 | 37,90 | 1659,88 | 1692,96 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 30,90 | 32,12 | 1406,68 | 1434,71 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
билгеләнгән тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге